Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының
«Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**29.11.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 29 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта һәм 10 сәгать 00 минутта "Әгерже муниципаль районының « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм ирекtән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1. «Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 30.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга ризамы, чөнки гражданнар җыены карарының 1 пунктындагы «үләт базын киртәләү» не мәсьәләләр арасыннан төшереп калдыру»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 546 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 297 кеше, бу 54,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 297 катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

2. Әгерже муниципаль районы « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан

(контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), I төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертергә:

**1) Паркны төзекләндерү (волейбол мәйданчыгы урнаштыру);**
**2) Урамнарны яктырту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау:**
- фонарьлар, лампалар, урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру, чишмәгә юлны яктырту, электрикка хезмәт хакы түләү;
**3) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;**
- сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;
**4) Торак пуктны төзекләндерү:**
- трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, дизель мае, запас частьләр сатып алырга; рөхсәтсез чүплекләрне бетерү, Исәнбай авылында чүп үләннәрен чабарга, урамнарны кардан чистартырга, трактористка хезмәт хакы түләү һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар.
- роторлы чапкыч өчен запас частьләр сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 546 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 296 кеше, бу 54,2% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 296 катнашучысы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Әгерҗе муниципаль районы « Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), I төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе

сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 700 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

**1) Паркны төзекләндерү (волейбол мәйданчыгы урнаштыру);**

**2) Урамнарны яктырту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау:**

- фонарьлар, лампалар, урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алыштыру, чишмәгә юлны яктырту, электрикка хезмәт хакы түләү;

**3) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;**

- сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

**4) Торак пуктны төзекләндерү:**

- трактор тоту һәм хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, дизель мае, запас частьләр сатып алырга; рөхсәтсез чүплекләрне бетерү, Исәнбай авылында чүп үләннәрен чабарга, урамнарны кардан чистартырга, трактористка хезмәт хакы түләү һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар.

- роторлы чапкыч өчен запас частьләр сатып алу.

4. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 30.10.2025 №1 карарны, гражданнар җыены карарының 1 пунктындагы «үләт базын киртәләү» не мәсьәләләр арасыннан төшереп калдыру сәбәпле, гамәлдән чыгарырга.

5. Карарны Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәдиев Р.Р.